СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОРКАЧЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык тимер юл разъезды пос., Гагарин урамы, 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**11 ноябрь 2024 ел** **№ 100**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2015 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Коркачык авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.10.2015 елның 9 номерлы карарына (28.04.2018 елның 80 номерлы, 06.09.2018 елның 91 номерлы, 27.12.2018 елның 111 номерлы, 28.11.2022 елның 55 номерлы, 12.09.2023 64 номерлы, 13.11.2023 69 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"4) 2,5 процентка карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларын;»

1.2. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елдан карата 2% :

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларын; Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларын.»

2. Әлеге карар законлы көченә 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма ул рәсми рәвештә игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач керә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Совет Рәисе,
Коркачык авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихҗанов